Зеленодольск муниципаль районы Советының
2025 елның 21 мартындагы
477 номерлы карарына
кушымта

.

«Зеленодольск - хезмәт батырлыгы шәһәре»
юбилей медален гамәлгә кую турында нигезләмә

1 статья. Гомуми нигезләмәләр.

1.1. Россия Федерациясе Президентының 2025 елның 15 гыйнварындагы 16 нчы Указы белән шәһәр халкының 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында җиңүгә ирешүгә керткән зур өлеше, сәнәгать предприятиеләрендә хәрби һәм граждан продукциясен өзлексез җитештерүне тәэмин итүе, шул ук вакытта массакүләм хезмәт батырлыгы һәм фидакарьлеге өчен Зеленодольск шәһәренә «Хезмәт батырлыгы шәһәре»дигән мактаулы исем бирелде.

1.2. «Зеленодольск – хезмәт батырлыгы шәһәре» юбилей медале (алга таба - юбилей медале) белән Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышы елларында шәһәрнең сәнәгать предприятиеләрендә хәрби һәм гражданлык продукциясен өзлексез җитештерүне тәэмин итүгә өлеш керткән гражданнар, Зеленодольск шәһәренең үсешенә һәм чәчәк атуына, Зеленодольск шәһәренең ролен һәм абруен күтәрүгә зур өлеш керткән гражданнар, Зеленодольск шәһәренең социаль-икътисадый үсешенә юнәлдерелгән хезмәттәге, эшчәнлектәге зур казанышлары өчен (алга таба - кандидатлар) бүләкләнәләр.

1.3. Юбилей медале бүләкләнүчегә социаль һәм башка ташламалар яисә өстенлекләр бирү өчен нигез булып тормый.

1.4. Кандидатларның үтенечнамәләрен һәм документларын Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы тарафыннан төзелгән һәм расланган Бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау буенча комиссия (алга таба – Комиссия) карый.

2 статья. «Зеленодольск - хезмәт батырлыгы шәһәре» юбилей медален сурәте һәм тасвирламасы.

2.1. «Зеленодольск – хезмәт батырлыгы шәһәре» юбилей медаленең сурәте һәм тасвирламасы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан әзерләнә һәм Комиссиягә тапшырыла.

2.2. Комиссия Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тәкъдим иткән юбилей медалендәге сурәтләрне карый һәм тасвирламаны килештерә.

2.3. Юбилей медаленең сурәте һәм тасвирламасы Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы тарафыннан раслана.

